РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.04.2022 Буа шәһәре № 106 Бк/к

«2022 - 2024 елларга Буа муниципаль районы территориясендә терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау» комплексы муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Терроризмга каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы, «Экстремистлык эшчәнлегенә каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль законнарын тормышка ашыру максатларында, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 октябрендәге 321Бк/к номерлы карары белән расланган «2022 - 2024 елларга Буа муниципаль районы территориясендә терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау» комплексы муниципаль программасына (алга таба–Программа) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Программаның 2.3 пунктын үзгәртергә һәм кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru/ адресы буенча районның рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов

Кушымта

| Төп чараларның исеме | Башкаручы | Төп чараларны үтәү вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Индикаторларның билгеләре | | | | Татарстан Республикасы Буа муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары исәбеннән финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 бурыч. Татарстан Республикасында терроризмга каршы аң формалаштыру | | | | | | | | | | |
| | | | | 2021 (база) ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | | 8 | 9 | 10 |
| 2.3. Халык белән мәгълүмати-аңлату эшләре алып бару өчен квалификацияле лектор-пропагандистларны җәлеп итүне тәэмин итү, аларга матди кызыксындыру каралган | Буа муниципаль районы башкарма комитеты, авыл җирлекләре башлыклары, | 2022 - 2024 еллар | Чакырылган лекторлар белән лекцияләр/чыгышлар саны | 0 | 1 | 1 | 1 | 10 | 10 | 10 |